ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.12.2020 Казан ш. № 527-105/тэ-2020

2021 елга Зеленодольск муниципаль районында «ТГК-16» акционерлык җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга җиткерелә торган җылылык энергиясе (егәрлеге) өчен тарифлар билгеләү хакында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя билгеләү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Зеленодольск муниципаль районында «ТГК-16» акционерлык җәмгыяте (алга таба – «ТГК-16» АҖ) тарафыннан кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга җиткерелә торган җылылык энергиясе (егәрлеге) өчен әлеге карар кушымтасына туры китереп, календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2021 елның 1 гыйнварыннан 2021 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л. Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
17.12.2020 № 527-105/тэ-2020
карарына кушымта

# «ТГК-16» АҖ тарафыннан кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) 2021 елга календарь буенча бүлгәләнгән тарифлар

| № т/с | Муниципаль берәмлекнең, җайга салучы оешманың аталышы, Тариф төре | Ел | су | Басым белән сайлап алынган пар | | | | Әче һәм редукцияләштерелгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 башлап 2,5 кг/см$^2$ кадәр | 2,5 башлап 7,0 кг/см$^2$кадәр | 7,0 башлап 13,0 кг/см$^2$кадәр | 13,0 кг/см$^2$ югары | |
| | Зеленодольск муниципаль районы | | | | | | | |
| 1 | «ТГК-16» АҖ | | | | | | | |
| 1.1 | Тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгәндә, – кулланучылар өчен | | | | | | | |
| | бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 1372,20 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 1411,03 | - | - | - | - | - |
| 1.2 | Халык (тарифлар НДС исәпкә алып күрсәтелде)* | | | | | | | |
| | бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 1646,64 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 1693,24 | - | - | - | - | - |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясының 6 пунктын үтәү максатларында аерып чыгарыла

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф чишелешләрен
кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм
теркәү бүлеге